Д.К. Галиуллин, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов

# ПЕДАГОГИКА ТАРИХЫ



УДК 377; 80/81
ББК 74.268.1 Тат–5
Г14

**Рецензентлар:**

**Р.Х. Шәймәрданов,** педагогика фәннәре докторы, профессор
**Р.Г. Габдрахманова,** педагогика фәннәре кандидаты, доцент
**Р.П. Хәсбиева,** педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Галиуллин Д.К., Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**
**Г14** Педагогика тарихы: лекцияләр курсы. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2014.– 156 б.

**ISBN 5-94113-048-3**

**УДК 377; 80/81**
**ББК 74.268.1 Тат–5**

**ISBN 5-94113-048-3**

**© Галиуллин Д.К., 2014**
**© Хуҗиәхмәтов Ә.Н., 2014**



# ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ИЛЕНЕҢ IX–X ГАСЫРЛАРДА МӘДӘНИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҮСЕШЕ ТАРИХЫННАН

IX гасыр ахыры – X гасыр башында Идел буендагы болгарларның ислам динен рәсми рәвештә кабул итүе Болгар иленең озак вакытлар дәвамында мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси үсешен билгели торган вакыйга була. Ул Болгар иленең дәүләт булып ныгуында, шәһәр тормышы, сәүдә, һөнәрчелек үсешендә яңа баскыч була. Болгар иле дөньядагы иң алга киткән ислам дәүләтләре белән тыгыз бәйләнешләр урнаштыра.

Багдад илчелеге Болгарга 922 елның маенда килеп җитә. Илчелекне Әхмәт ибн Фадлан җитәкли. Болгар илендә бу чорда идарә иткән Алмыш патша Багдад илчелеген зур хөрмәт белән каршы ала. Күзәтүчән, тапкыр кеше булган Әхмәт ибн Фадлан Болгар илендә һәм юлда күргәннәрен бик җентекләп язып бара. Аның «Рисалә»се («Язма», «Юллама») безнең көннәргә кадәр килеп җиткән һәм ул кыйммәтле тарихи чыганак булып хезмәт итә. Ул чакта ислам диненең үзәге Багдад шәһәрендә булган. Багдад дөньядагы иң зур өч шәһәрнең берсе булып саналган, анда төрле халыклар яшәгән. Аерым бер төркемне төрки халыклар тәшкил иткән. Аз санда булсалар да, ил тормышында аларның йогынтысы сизелерлек булган. Ислам һәм төрки дөньясының кайчандыр бер-берсенә каршы торуы, соңрак якынаюы һәм үзара керешеп-аралашып китүенең тарихы гарәп һәм фарсы әдәбиятында киң чагылыш тапкан. Хәлифәлектә яшәгән төркиләр әлеге ислам җәмгыятендә үз урыннарын тапканнар – дини-хокукый фикер өлкәсендә, фәндә, әдәбиятта үзләрен яхшы хәзерлекле кешеләр итеп танытканнар; дәүләт хезмәтендәге чиновниклар яисә гади шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр булганнар; башта әсирлеккә төшкән тоткыннар яисә сатып алынган коллар бу-